ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, E-Mail:bkbioresursy@tatarstan.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ Казан шәһәре Боерык

20.01.2026 № 18 - од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 11 ноябрендәге 345-од номерлы боерыгы белән расланган Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

«Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына туры китерү максатларында **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2020 елның 11 ноябрендәге 345-од номерлы боерыгы белән расланган Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасы Биологик

ресурслар буенча дәүләт комитетының 2021 елның 4 июнендәге 163-од номерлы, 2021 елның 31 августындагы 255-од номерлы, 2021 елның 28 сентябрендәге 293-од номерлы, 2022 елның 12 апрелендәге 84-од номерлы, 2023 елның 07 августындагы 227-од номерлы, 2025 елның 16 маендагы 104-од номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән), яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә, дәүләт хезмәтләре күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга регламентларның нигезләмәләрен үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының 2020
елның 11 ноябрендәге 345-од
номерлы боерыгы белән
расланган (Татарстан
Республикасы Биологик
ресурслар буенча дәүләт
комитетының 2026 елның
20.01. №18-од номерлы боерыгы
редакциясендә)

# Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – дәүләт хезмәте) планлаштырыла торган торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объекты параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм региональ әһәмияттәге махсус саклanылучы табигать территориясе чикләрендә җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштыруның рөхсәт ителүе (рөхсәт ителмәве) турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели(«Махсус сакланылучы табигать территорияләре турында» 1995 елның 14 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның $3^1$ статьясында күрсәтелгән торак пунктлардан тыш).

1.2. Гариза бирүчеләр: юридик затлар (шул исәптән чит ил юридик затлары), шәхси эшмәкәрләр, гражданнар (алга таба – гариза бирүчеләр, төзүчеләр).

Гариза бирүчеләрнең мәнфәгатьләрен гариза бирүче тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар (алга таба – гариза бирүченең вәкиле) тәкъдим итәргә мөмкин.

1.3. Дәүләт хезмәте гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә, алар турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (http://gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал), «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы» төбәк мәгълүмат системасында

(http://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы), шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәте атамасы.

Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты).

Дәүләт хезмәте Дәүләт комитетының Биологик төрлелек бүлеге (алга таба – Бүлек) тарафыннан күрсәтелә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе:

1) шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның мөмкинлеге турында хәбәрнамә ... (алга таба – Туры килү турында хәбәрнамә)(форма Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү өчен кирәкле хәбәрнамәләр формаларын раслау турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 591/пр номерлы боерыгы белән расланды (алга таба - 591/пр номерлы боерык);

2) шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яисә) шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның мөмкин булмавы турында хәбәрнамә (алга таба – Туры килмәү турында хәбәрнамә) (форма 591/пр боерыгы белән расланган);

3) кире кайтару турында хәбәрнамә (әлеге Регламентка 5 нче кушымта).

2.3.2. Гариза бирүче Республика порталында яисә Бердәм порталда шәхси кабинет аша мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә Республика порталында яисә Бердәм порталда шәхси кабинетына җибәрелә.

Гариза бирүче сайлавы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе шулай ук Дәүләт комитетында шәхсән Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи затының

мөһере һәм имзасы белән таныкланган кәгазьдә бастырылган электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә.

Гариза бирүченең сайлавы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе шулай ук «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба – КФҮ) кәгазьдә бастырылган, Дәүләт комитетының тиешенчә вәкаләтле вазыйфаи заты яисә КФҮ хезмәткәренең мөһере һәм имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе рәвешендә бирелә.

Гариза бирүченең сайлавы буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе кәгазьдә бастырылган, Дәүләт комитетының вәкаләтле вазыйфаи затының мөһере һәм имзасы белән таныкланган электрон документ экземплярлы рәвешендә хәбәрнамә белән почта аша җибәрү рәвешендә, шулай ук гариза бирүче күрсәткән электрон почта адресына электрон документ рәвешендә җибәрелә.

2.3.3. Мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында реестр язмасын булдыру зарурлыгы юк.

2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле хәбәрнамә һәм документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән, электрон почта аша яисә почта аша җибәреп тапшырылган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь вакыты хәбәрнамә кергән көннән алып җиде эш көне тәшкил итә. Хәбәрнамә дигәндә, әлеге Регламент максатларында планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә һәм планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яисә реконструкцияләү параметрларын үзгәртү турында хәбәрнамә (алга таба – хәбәрнамә) аңлашыла. (хәбәрнамә формалары 591/пр боерыгы белән расланган).

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле хәбәрнамә һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша тапшырылган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты эш номенклатурасы һәм Бердәм порталда, Төбәк порталында шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документларны тикшерү» статусы нигезендә хәбәрнамәгә номер бирелгән көннән алып җиде эш көне тәшкил итә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле хәбәрнамә һәм документлар КФҮгә тапшырылган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүнең максималь срогы документлар дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга тапшырылган көннән алып җиде эш көне тәшкил итә.

Әгәр шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә реконструкцияләү федераль яисә төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылса һәм хәбәрнамәдә мондый шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә реконструкцияләү планлаштырыла торган типовой архитектура чишелеше күрсәтелмәсә, Дәүләт комитеты түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

1) хәбәрнамә кергән көннән алып өч эш көненнән дә артык булмаган вакытта, аны кире кайтару өчен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $51^1$ статьясындагы 6 өлешендә каралган нигезләр булмаганда (алга таба-РФ ГрК), шул

исәптән, ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетына шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының тышкы кыяфәте турында хәбәрнамә һәм аңа кушымта итеп бирелгән тасвирлама җибәрә;

2) шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән рөхсәт ителгән иң чик параметрларына, РФ ШтК, башка федераль законнарда билгеләнгән һәм хәбәрнамә кергән көнгә гамәлдә булган капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килү-килмәвен, шулай ук шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегеннән файдалануга рөхсәт ителгән һәм Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм хәбәрнамә кергән көнгә гамәлдә булган чикләүләр нигезендә урнаштыру мөмкинлеген тикшерә;

3) хәбәрнамә кергән көннән алып егерме эш көненнән дә соңга калмыйча, төзүчегә хәбәрнамәдә ул үзе билгеләгән ысул белән Туры килү турында хәбәрнамә йә Туры килмәү турында хәбәрнамә җибәрә.

Хәбәрнамә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар гариза бирүче тарафыннан шәхсән, электрон почта аша яисә почта аша җибәреп тапшырылган очракта, Кире кайтару турында хәбәрнамә, хәбәрнамә һәм аңа беркетелгән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар белән бергә гариза бирүчегә хәбәрнамә кергән көннән алып өч эш көне эчендә җибәрелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле хәбәрнамә һәм документлар Бердәм порталда, Республика порталында шәхси кабинет аша тапшырылган очракта, Кире кайтару турында хәбәрнамә гариза бирүчегә эш номенклатурасы һәм Бердәм порталда, Төбәк порталында шәхси кабинетта чагылдырыла торган «Документларны тикшерү» статусы нигезендә хәбәрнамәгә номер бирелгән көннән алып өч эш көне эчендә җибәрелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле хәбәрнамә һәм документлар КФҮгә тапшырылган очракта, Кире кайтару турында хәбәрнамә һәм аңа беркетелгән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар белән бергә гариза бирүчегә документлар дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга тапшырылган көннән алып өч эш көне эчендә җибәрелә.

Гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, Дәүләт комитеты һәм КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле хәбәрнамәне һәм теркәлә торган документларны Дәүләт комитетына тапшыру тәэмин ителә. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытына хәбәрнамәнең КФҮдә булу вакыты һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен Дәүләт комитетыннан КФҮгә тапшыру вакыты кертелми.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү алу Россия Федерациясе законнарында каралмаган.

2.6. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы сорату биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

Гариза бирүчене кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен дәүләт хезмәте күрсәтүгә чират билгеләнмәгән.

2.7. Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты

Гариза бирүче шәхсән Дәүләт комитетына, почта аша, электрон почта аша мөрәҗәгать иткәндә теркәлү хәбәрнамә һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла. Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән хәбәрнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә.

Гариза бирүче хәбәрнамәне Бердәм портал, Республика порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче хәбәрнамә биргән көнне Бердәм порталдагы, Республика порталындагы шәхси кабинетына һәм электрон почта аша хәбәрнамәнең теркәлү номеры һәм хәбәрнамә бирү датасы күрсәтелгән, хәбәрнамә җибәрелүен раслый торган хәбәрнамә ала.

КФҮ аша хәбәрнамә кергәндә, хәбәрнамә КФҮдән кергән көнне Дәүләт комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр Дәүләт комитетының рәсми сайтында, Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган.

2.9. Дәүләт хезмәтенең үтемлелеге һәм сыйфаты күрсәткечләре.

Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдаланырлык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре Дәүләт комитетының рәсми сайтында, Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган.

2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү хакында.

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.10.2. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәткәндә, гариза бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Бердәм порталда һәм Республика порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында соратуны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның

(алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 16 статьясындагы 1 өлешенең $7^2$ пункты нигезендә электрон образлары элек таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаларны башкару барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Дәүләт комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) карата Бердәм портал, Республика порталы, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелгәндә кылынган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган мәгълүмат системасы аша, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру башка формада өстәмә сорату бирү соратуның электрон формасын Бердәм порталда яисә Республика порталында тутыру юлы белән башкарыла (башка формада өстәмә сорату бирү таләп ителми).

2.10.3. Гариза бирүче, хәбәрнамәне электрон формада Бердәм портал яисә Республика порталы аша тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда яки Республика порталында авторизация үтә;

Бердәм порталда яисә Республика порталында электрон хәбәрнамә формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон хәбәрнамә формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яисә документларның электрон образларын электрон хәбәрнамә формасына беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон хәбәрнамә формасында ризалык турында тиешле тамга куя); хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый;

тутырылган электрон хәбәрнамә җибәрә (электрон хәбәрнамә формасында тиешле төймәгә баса);

электрон хәбәрнамә җибәрү турында хәбәрнамә ала.

Хәбәрнамә язганда, түбәндәге мөмкинлекләр бирелә:

1) хәбәрнамәне һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны күчереп алу һәм саклап калу мөмкинлеге;

2) электрон хәбәрнамә формасының күчермәсен кәгазьдә бастыру мөмкинлеге;

3) элек электрон хәбәрнамә формасына кертелгән кыйммәтләрне кулланучы теләге белән теләсә кайсы вакытта, шул исәптән кертү хаталары килеп чыкканда һәм хәбәрнамәнең электрон формасына кыйммәтләрне яңадан кертү өчен кире кайтарганда саклау;

4) гариза бирүче ЕСИАда урнаштырылган мәгълүматны һәм, ЕСИАда булмаган мәгълүматларга кагылышлы өлештә Бердәм порталда, Республика

порталында басылган мәгълүматларны кулланып мәгълүматны керткәнче, хәбәрнамәнең электрон формасы кырын тутыру;

5) элек кертелгән мәгълүматны югалтмыйча, хәбәрнамәнең электрон формасын тутыруның теләсә кайсы этабына кайту мөмкинлеге;

6) гариза бирүченең үзенең элек биргән хәбәрнамәләренә кимендә бер ел эчендә, шулай ук өлешчә формалаштырылган хәбәрнамәләренә кимендә өч ай эчендә керү мөмкинлеге.

2.10.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр» гамәли платформасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кулланыла.

2.10.5. Татарстан Республикасы Дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат мәгълүмати стендларда һәм Дәүләт комитетының рәсми сайтында урнаштырыла.

2.10.6. Хәбәрнамәне КФҮ аша тапшырган очракта, КФҮнең гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге бар.

КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәткәндә, консультация бирүне, документлар кабул итү һәм бирүне КФҮ белгече башкара.

Гариза бирүче КФҮ аша мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм документларны хәбәрнамәне теркәү көненнән алып бер эш көне эчендә Дәүләт комитетына тапшыру тәэмин ителә.

КФҮдә гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе бирелә, шул исәптән Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча КФҮгә җибәрелгән электрон документларның эчтәлеген раслый торган кәгазь документлар, шулай ук документлар, шул исәптән Дәүләт комитетының мәгълүмат системаларыннан кәгазьдә төзелгән һәм таныкланган өземтәләр бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, Дәүләт комитеты белән КФҮнең үзара хезмәттәшлеге тәртибе Дәүләт комитеты белән КФҮ арасында төзелә торган килешү белән, ә КФҮнең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлек тәртибе – КФҮнең эш регламенты белән җайга салына.

2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге.

Гариза бирүче үзе тапшыра торган документларга һәм мәгълүматка һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиеш булган гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы документларга бүленеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен закон һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, яисә андый документларның булмавын күрсәтү шушы Регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән.

Планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә формасы, планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яисә реконструкцияләү параметрларын үзгәртү турында хәбәрнамә формасы 591/пр боерыгы белән расланган.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен

күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) хәбәрнамә вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү керми торган дәүләт хакимияте органына тапшырылган;

2) тапшырылган документлар дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчләрен югалткан (шәхесне раслый торган документ; гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап күрсәтелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта);

3) кәгазьдә тапшырылган документларда законнар белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган текстта бетерү һәм төзәтү бар;

4) электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган зыяннар бар;

5) Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле хәбәрнамә һәм документлар электрон формада, аларны бирү форматына карата таләпләрне бозып тапшырылган һәм (яки) укылмый;

6) 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү ачыкланган.

Хәбәрнамәне кабул итүдән баш тарткан очракта, гариза бирүчегә кире кайтару турында хәбәрнамә (әлеге Регламентка 5 нче кушымта нигезендә) хәбәрнамә кергән көннең иртәгесеннән бер эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә (тапшырыла).

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.12.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр

1. Туры килмәү турында хәбәрнамә җибәрү өчен нигезләр:

а) шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән чик параметрларына яисә РФ ШтК, башка федераль законнарда билгеләнгән һәм планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә кергән көнгә гамәлдә булган капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килмәве;

б) хәбәрнамәдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштыру җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре һәм (яисә) Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә кергән көнгә гамәлдә булган чикләүләр нигезендә рөхсәт ителми;

в) хәбәрнамә җир кишәрлегенә хокуклары булмау сәбәпле төзүче булмаган зат тарафыннан тапшырылган яисә җибәрелгән;

г) РФ ШтК $51^1$ статьясының 9 өлешендә күрсәтелгән срокта Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетыннан шәхси торак

төзелеше объектының яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен тасвирлауның тарихи җирлекнең сак предметына һәм шәһәр төзелеше регламентында федераль яисә төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектура чишелешләренә карата таләпләргә туры килмәве турында хәбәрнамә керде.

2. Хәбәрнамәне кире кайтару өчен нигезләр:

а) хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләр булмаган очракта:

төзүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (физик зат өчен);

төзүченең исеме һәм урнашу урыны (юридик зат өчен), шулай ук юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры, мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булса;

җир кишәрлегенең кадастр номеры (булган очракта), адресы яисә җир кишәрлегенең урнашу урыны тасвирламасы;

төзүченең җир кишәрлегенә хокукы турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлегенә башка затларның (мондый затлар булганда) хокуклары булу турында белешмәләр;

җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан (шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты) файдалануның рөхсәт ителгән төре турында белешмәләр;

планлаштырыла торган төзелеш яисә реконструкцияләү максатларында хәбәрнамә бирелгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган параметрлары, шул исәптән җир кишәрлеге чикләреннән чигенүләр турында белешмәләр;

шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының мөстәкыйль күчемсез милек объектларына бүлү өчен каралмавы турындагы белешмәләр;

төзүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы;

төзүчегә хәбәрнамәләр җибәрү ысулы;

эскроу счетыннан файдаланып төзелеш подряды шартнамәсе турында белешмәләр, мондый шартнамә нигезендә шәхси торак төзелеше объектын төзү эшләрен башкаручы зат турында белешмәләрне дә кертеп («Эскроу счетларыннан файдаланып, төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү турында» 2024 елның 22 июлендәге 186-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси торак төзелеше объектын төзегәндә);

б) хәбәрнамәгә түбәндәге документлар беркетелмәгән:

1) әгәр хәбәрнамә төзүче вәкиле тарафыннан җибәрелгән булса, төзүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;

2) юридик затны чит дәүләт законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның рус теленә таныкланган тәрҗемәсе, әгәр төзүче чит ил юридик заты булса;

3) шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының тышкы кыяфәте тасвирламасы, шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын төзү яки реконструкцияләү федераль яисә төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе

чикләрендә планлаштырылган очракта, РФ ШтК 51[1] статьясының 5 өлешендә каралган очрактан тыш. Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының тышкы кыяфәтен тасвирлау текст формасында тасвирлауны һәм график тасвирлауны үз эченә ала. Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының тышкы кыяфәте тасвирламасы текст формасында шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының параметрларын күрсәтүне, аларның тышкы кыяфәтенең төсен, шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының тышкы кыяфәтен билгели торган файдалануга планлаштырыла торган төзелеш материалларын күрсәтүне, шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының аларга карата таләпләр Шәһәр төзелеше регламентында капиталь төзелеш объектының архитектура чишелешләренә карата таләпләр сыйфатында билгеләнгән башка характеристикалары тасвирламасын үз эченә ала. График тасвирлама шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен, шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының фасадларын һәм конфигурациясен дә кертеп, сурәтләүдән гыйбарәт.

Әлеге пунктның 2 пунктчасында күрсәтелгән очракларда хәбәрнамә һәм аңа кушып бирелгән документлар гариза бирүчегә кире кайтарыла һәм хәбәрнамә җибәрелмәгән дип санала.

2.12.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, Дәүләт комитетына гариза бирүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп хәбәр итә.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Регламентка 4 нче кушымтада китерелгән.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү вакытлары

3.1. Гариза бирүче һәм (яисә) гариза бирүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук гариза бирүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен (дәүләт хезмәтен күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында Карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш), бәяләү үткәрелә торган административ процедураны, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң гариза бирүчегә карата чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны) бүлүне күздә тоткан административ процедураны, гариза бирүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында ике һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатлау рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын гамәлгә ашыру каралмаган.

3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлгә ашырыла торган административ

процедуралар исемлеге:

1) гариза бирүченең профилен билгеләү;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

5) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

3.3. Дәүләт хезмәте алдан (проактив) режимда күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны карау статусын үзгәртү турында гариза бирүчегә хәбәр итү ысуллары

Гариза бирүчегә хәбәрнамәне карау статусының үзгәрүе турында хәбәр итү автомат рәвештә Бердәм порталда, Республика порталында гариза бирүченең шәхси кабинетында, Дәүләт комитетына һәм КФҮгә шәхсән кабул иткәндә гамәлгә ашырыла.

Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында административ регламентка 1 нче кушымта

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге

1. Дәүләт хезмәте – шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте

2. Гариза бирүчеләр – юридик һәм физик затлар, шәхси эшкуарлар;

3. Гариза бирүче вәкиле – гариза бирүче тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар;

4. Республика порталы – «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы» төбәк мәгълүмат системасы (http://uslugi.tatarstan.ru);

5. Бердәм портал – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (http://gosuslugi.ru);

6. Дәүләт комитеты – Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты;

7. Бүлек – Дәүләт комитетының Биотөрлелек бүлеге;

8. КФҮ – «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;

9. Туры килү турында хәбәрнамә – Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше яки реконструкция турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә

10. Туры килмәү турында хәбәрнамә – Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше яки реконструкция турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә

11. 63-ФЗ номерлы Федераль закон – «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон;

12. РФ ШтК – Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы;

13. Параметрлар үзгәрү турында хәбәрнамә – шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше яки реконструкцияләү параметрларының үзгәреше турында хәбәрнамә;

14. Планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә – планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә; планлаштырыла торган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яисә реконструкцияләү параметрларын үзгәртү турында хәбәрнамә;

15. 210-ФЗ номерлы Федераль закон – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

16. 591/пр номерлы боерык – Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү өчен кирәкле хәбәрнамәләр формаларын раслау турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 591/пр номерлы боерыгы;

Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында административ регламентка 2 нче кушымта

Гариза бирүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары

| № | Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе | Гариза бирүченең аерым билгесе исеме | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1 | Туры килү турында хәбәрнамә | Гариза бирүче – планлаштырылган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән зат | 1А |
| 2 | | Гариза бирүче – планлаштырылган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән юридик зат | 2А |
| 3 | | Гариза бирүче – планлаштырылган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән шәхси эшкуар | 3А |
| 4 | | Гариза бирүче вәкиле – планлаштырылган | 4А |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән гражданин, юридик зат, шәхси эшкуар вәкиле | |
| 5 | | Гариза бирүче – планлаштырылган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яисә реконструкцияләү параметрларын үзгәртү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән гражданин | 5А |
| 6 | | Гариза бирүче – планлаштырылган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яисә реконструкцияләү параметрларын үзгәртү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән юридик зат | 6А |
| 7 | | Гариза бирүче – планлаштырылган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яисә реконструкцияләү параметрларын үзгәртү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән шәхси эшкуар | 7А |
| 8 | | Гариза бирүче вәкиле – шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше яки реконструкцияләү параметрларының үзгәреше турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән гражданин, юридик зат, шәхси эшкуар вәкиле | 8А |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 | | Гариза бирүче – планлаштырылган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән чит гражданины булган юридик зат | 9А |
| 10 | | Гариза бирүче вәкиле – планлаштырылган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән чит гражданины булган юридик зат вәкиле | 10А |
| 11 | | Гариза бирүче – планлаштырылган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яисә реконструкцияләү параметрларын үзгәртү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән чит ил гражданины булган юридик зат | 11А |
| 12 | | Гариза бирүче вәкиле – планлаштырылган шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектын төзү яисә реконструкцияләү параметрларын үзгәртү турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать иткән юридик зат вәкиле | 12А |

Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында административ регламентка 3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның исемлеге | Документлар тапшыруга таләпләр | Документлар тапшыру ысуллары |
|---|---|---|---|---|
| *Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза бирүче мөстәкыйль рәвештә тапшыра торган документларның тулы исемлеге* | | | | |
| 1 | 1А, 2А, 3А, 4А, 9А, 10А | Планлаштырылган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яки реконструкцияләү турында хәбәрнамә | Форма 591/пр боерыгы белән расланган | Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; Республика порталы, Бердәм портал, КФҮ аша |
| 2 | 5А, 6А, 7А, 8А, 11А, 12А | Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше яки реконструкцияләү параметрларының үзгәреше турында хәбәрнамә | | |
| 3 | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А | Җир кишәрлегенә хокук билгеләүче документлар | Әгәр аңа хокуклар Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт Реестрында теркәлмәгән булса | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Документлар 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) кәгазь чыганакларда һәм электрон документлар рәвешендә бирелә.<br><br>Тапшырыла торган документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; КФҮ |
| | | | Гаризага беркетелә торган электрон документлар файл рәвешендә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларында 50 Мбайт тан артмаган зурлыкта җибәрелә. Тапшырыла торган электрон документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | Дәүләт комитетына Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | 4А, 8А,10А, 12А | Гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ | Документлар 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) кәгазь чыганакларда һәм электрон документлар рәвешендә бирелә.<br><br>Тапшырыла торган документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; КФҮ |
| | | | Гаризага беркетелә торган электрон документлар файл рәвешендә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларында 50 Мбайт тан артмаган зурлыкта җибәрелә. Тапшырыла торган электрон документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | Дәүләт комитетына Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | 9А, 10А | Юридик затны чит дәүләт законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның рус теленә таныкланган тәрҗемәсе | Документлар 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) кәгазь чыганакларда һәм электрон документлар рәвешендә бирелә.<br><br>Тапшырыла торган документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; КФҮ |
| | | | Гаризага беркетелә торган электрон документлар файл рәвешендә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларында 50 Мбайт тан артмаган зурлыкта җибәрелә. Тапшырыла торган электрон документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | Дәүләт комитетына Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 6 | 1А, 2А, 3А, 4А, 9А, 10А | Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының тышкы кыяфәте тасвирламасы (шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын төзү яки реконструкцияләү федераль яисә төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылган очракта, РФ ШтК $51^{1}$ статьясының 5 өлешендә каралган очрактан тыш) | Документлар 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) кәгазь чыганакларда һәм электрон документлар рәвешендә бирелә.<br><br>Тапшырыла торган документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; КФҮ |
| | | | Гаризага беркетелә торган электрон документлар файл рәвешендә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларында 50 Мбайт тан артмаган зурлыкта җибәрелә. Тапшырыла торган электрон документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | Дәүләт комитетына Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә |
| 7 | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, | Гариза бирүченең яисә гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклый торган документ | Шәхесне таныклый торган документ; | Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 9А, 10А, 11А, 12А | | күрсәтелгән зат дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче вәкиле вәкаләтләрен таныклый торган документ | |
| *Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, гариза бирүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы кирәкле документларның тулы исемлеге, чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тәкъдим ителергә тиеш* | | | | |
| 1 | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А | Әгәр хокук әлеге реестрда теркәлгән булса, җир кишәрлегенә Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан өземтә (гариза бирүче документларны мөстәкыйль тапшырмаган очракта) (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә) | Документлар 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) кәгазь чыганакларда һәм электрон документлар рәвешендә бирелә. Тапшырыла торган документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын таныйрга мөмкинлек бирергә тиеш | Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; КФҮ |
| | | | Гаризага беркетелә торган электрон документлар файл рәвешендә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларында 50 Мбайт тан артмаган зурлыкта җибәрелә. Тапшырыла торган | Дәүләт комитетына Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | электрон документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | |
| 2 | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А | Шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тышкы кыяфәте тасвирламасының тарихи җирлекнең сак предметына һәм шәһәр төзелеше регламентында федераль яисә төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектура карарларына карата таләпләргә туры килүе яисә туры килмәве турында белешмәләр (шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын төзү яисә реконструкцияләү федераль яисә төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылса һәм планлаштырыла торган төзелеш турындагы хәбәрнамәдә типовой архитектура чишелеше күрсәтелмәсә) (Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитетына) | Документлар 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) кәгазь чыганакларда һәм электрон документлар рәвешендә бирелә. Тапшырыла торган документларның сыйфаты документ текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | Дәүләт комитетына шәхсән мөрәҗәгать иткәндә; почта аша җибәреп; электрон почта аша; КФҮ |
| | | | Гаризага беркетелә торган электрон документлар файл рәвешендә pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларында 50 Мбайт тан артмаган зурлыкта җибәрелә. Тапшырыла торган электрон документларның сыйфаты документ | Дәүләт комитетына Республика порталы, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | текстын тулысынча укырга һәм документ реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш | |

Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм шәхси торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында административ регламентка 4 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

| № | Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге, һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Гариза бирүчеләрнең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|
| Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы соратуны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр | | |
| 1 | Хәбәрнамә вәкаләтләренә дәүләт хезмәте күрсәтү керми торган дәүләт хакимияте органына тапшырылган | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |
| 2 | Тапшырылган документлар дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткән вакытка үз көчләрен югалткан (шәхесне раслый торган документ; гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ, дәүләт хезмәте күрсәтүне сорап күрсәтелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта); | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |
| 3 | Кәгазьдә тапшырылган документларда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган тәртиптә текстта бетерү һәм төзәтү бар | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |
| 4 | Электрон рәвештә тапшырылган документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларда булган | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә кулланырга мөмкинлек бирми торган зыяннар бар | 12А |
| 5 | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле хәбәрнамә һәм документлар электрон формада, аларны бирү форматына карата таләпләрне бозып тапшырылган һәм (яки) укылмый | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |
| 6 | 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясында билгеләнгән көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаның чынлыгын тану шартларын үтәмәү ачыкланган | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |
| | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр | |
| 1 | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |
| | Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр | |
| | Туры килмәү турында хәбәрнамә җибәрү өчен нигезләр | |
| 1 | Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган төзелеш турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларының капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында билгеләнгән чик параметрларына яисә РФ ШтК, башка федераль законнарда билгеләнгән һәм планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә кергән көнгә гамәлдә булган капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләргә туры килмәве | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |
| 2 | Хәбәрнамәдә күрсәтелгән планлаштырылган шәхси торак төзелеше объектын яисә бакча йортын урнаштыру җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре һәм (яисә) Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамә кергән көнгә гамәлдә булган чикләүләр нигезендә рөхсәт ителми | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |
| 3 | Җир кишәрлегенә хокуклары булмау сәбәпле төзүче булмаган зат тарафыннан тапшырылган яисә җибәрелгән хәбәрнамә | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |
| 4 | Шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тышкы кыяфәте тасвирламасының тарихи җирлекнең сак предметына һәм шәһәр төзелеше регламентында федераль яисә төбәк әһәмиятендәге | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |

| | | |
|---|---|---|
| | тарихи җирлек территориясе чикләрендә урнашкан территориаль зонага карата билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының архитектура карарларына карата таләпләргә туры килмәве турында хәбәрнамә | |
| Хәбәрнамәне кире кайтару өчен нигезләр | | |
| 1 | Хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләрнең булмавы:<br>- төзүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (физик зат өчен);<br>- төзүченең исеме һәм урнашу урыны (юридик зат өчен), шулай ук юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәве турында язманың дәүләт теркәү номеры һәм салым түләүченең идентификация номеры, мөрәҗәгать итүче чит ил юридик заты булса;<br>- җир кишәрлегенең кадастр номеры (булган очракта), адресы яисә җир кишәрлегенең урнашу урыны тасвирламасы;<br>- төзүченең җир кишәрлегенә хокукы турында белешмәләр, шулай ук җир кишәрлегенә башка затларның (мондый затлар булганда) хокуклары булу турында белешмәләр;<br>- җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан (шәхси торак төзелеше объекты яисә бакча йорты) файдалануның рөхсәт ителгән төре турында белешмәләр;<br>- төзелеш яисә реконструкцияләү максатларында хәбәрнамә бирелгән шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының планлаштырыла торган параметрлары, шул исәптән җир кишәрлеге чикләреннән чигенүләр турында белешмәләр;<br>- шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының мөстәкыйль күчемсез милек объектларына бүлү өчен каралмавы турындагы белешмәләр;<br>- төзүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы;<br>- төзүчегә хәбәрнамәләр җибәрү ысулы;<br>- эскроу счетыннан файдаланып төзелеш подряды шартнамәсе турында белешмәләр, мондый шартнамә нигезендә шәхси торак төзелеше объектын төзү эшләрен башкаручы зат турында белешмәләрне дә кертеп («Эскроу счетларыннан файдаланып, төзелеш подряды шартнамәләре буенча торак йортлар төзү | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |

| | | |
|---|---|---|
| | турында» 2024 елның 22 июлендәге 186-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси торак төзелеше объектын төзегәндә); | |
| 2 | Түбәндәге документлар булмаганда:<br>1) әгәр хәбәрнамә төзүче вәкиле тарафыннан җибәрелгән булса, төзүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>2) юридик затны чит дәүләт законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның рус теленә таныкланган тәрҗемәсе, әгәр төзүче чит ил юридик заты булса;<br>3) шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының тышкы кыяфәте тасвирламасы, шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын төзү яки реконструкцияләү федераль яисә төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырылган очракта, РФ ШтК $51^1$ статьясының 5 өлешендә каралган очрактан тыш. Шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының тышкы кыяфәтен тасвирлау текст формасында тасвирлауны һәм график тасвирлауны үз эченә ала. Шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен текст рәвешендә тасвирлау шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының параметрларын күрсәтүне, аларның тышкы кыяфәтенең төсен, шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының тышкы кыяфәтен билгели торган файдалануга планлаштырыла торган төзелеш материалларын күрсәтүне, шәхси торак төзелеше яисә бакча йорты объектының аларга карата таләпләр Шәһәр төзелеше регламентында капиталь төзелеш объектының архитектура чишелешләренә карата таләпләр сыйфатында билгеләнгән башка характеристикалары тасвирламасын үз эченә ала. График тасвирлама шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының тышкы кыяфәтен, шәхси торак төзелеше объектының яисә бакча йортының фасадларын һәм конфигурациясен дә кертеп, сурәтләүдән гыйбарәт. | 1А, 2А, 3А, 4А, 5А, 6А, 7А, 8А, 9А, 10А, 11А, 12А |

Шәхси торак төзелеше яисә бакча
йорты объектының планлаштырыла
торган төзелеше турында
хәбәрнамәдә күрсәтелгән
параметрларның билгеләнгән
параметрларга туры килүе һәм
шәхси торак төзелеше объектын яки
бакча йортын җир кишәрлегендә
урнаштыруның рөхсәт ителүе
турында хәбәрнамә җибәрү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау
турында административ регламентка
5 нче кушымта

Форма

Кемгә: ______________________________
(физик затның фамилиясе, исеме, атасының
исеме (булган очракта)

______________________________
/ юридик затның

______________________________
исеме)

Кире кайтару турында хәбәрнамә

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты
___________________________________________________________
(оешма исеме, ИНН/КПП, ОГРН,

___________________________________________________________
урнашкан урыны, физик затның Ф.И.А. (булганда), паспорт белешмәләре, теркәлү адресы)

___________________________________________________________
дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту / дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итү турында хәбәр итә: (кирәклесенең астына сызарга)

___________________________________________________________
(дәүләт хезмәте атамасы)

Баш тарту сәбәбе: ___________________________________________
_________________________

______________________________ ____________ ______________________________
(вазыйфасы) (имза) Ф.И.А. (булган очракта),